ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

30.03.2021 ел　　　　Баулы шәһәре　　　　№49

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшьләр эшкуарлыгына ярдәм» муниципаль программасын раслау турында

Яшьләрне Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшьләр эшкуарлыгына ярдәм» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 30 мартындагы
49 номерлы карары белән
расланган

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшьләр эшкуарлыгына ярдәм»
МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## I. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Программа исеме | 2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшьләр эшкуарлыгына ярдәм» муниципаль программасы (алга таба - Программа) | | |
| Программага заказ бирүче | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты | | |
| Программа координаторы | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге»<br>«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ | | |
| Программаны эшләүче | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге»;<br>«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ | | |
| Программа максаты | Яшьләрне Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә җәлеп итү өчен шартлар тудыру | | |
| Программа бурычлары | Программаның бурычлары түбәндәгеләр:<br>- яшь кешеләрне эшкуарлык эшчәнлегенә күпләп җәлеп итү өчен мотивация булдыру;<br>- яшь эшкуарларны сыйфатлы укыту, мөстәкыйль бизнес алып бару күнекмәләрен формалаштыру;<br>- эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә яшьләрне мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү;<br>- эшлекле яшьләр өчен уку-укыту программаларын эшләү һәм гамәлгә кертү;<br>- үз бизнес-проектларын әзерләү һәм яклау күнекмәләрен үстерү. | | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2021-2025 еллар | | |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлгәләп, программаны финанслау күләмнәре | Ел | Фаразланган акча күләме, мең сум. | |
| | | Муниципаль район бюджеты | Бюджеттан тыш чыганаклар |
| | 2021 | 10,00 | - |
| | 2022 | 10,00 | - |
| | 2023 | 10,00 | - |
| | 2024 | 10,00 | - |
| | 2025 | 10,00 | - |
| | Барлыгы: | 50,00 | - |
| | Финанслау күләмнәре - бюджет чыганаклары | | |

| | |
|---|---|
| | Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә, шулай ук уртак финанслауга программа чараларын федераль һәм республика бюджетларыннан акча бүлеп бирергә тиеш. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторларын) тормышка ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны гамәлгә ашыру Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк, шул исәптән:<br>- эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә яшьләрне мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү;<br>- яшь эшмәкәрләргә ярдәм итү чараларында (форумнарда, түгәрәк өстәлләрдә, ачык лекцияләрдә һ.б.) катнашкан яшь кешеләр санын 500 кешегә кадәр арттыру;<br>- социаль киеренкелекне киметү;<br>- эш урыннары санын арттыру;<br>- яшь кешеләр тарафыннан булдырылган коммерцияле предприятиеләрнең табыш күләмен арттыру. |

## II. Гомуми нигезләмәләр

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында яшьләр эшкуарлыгына ярдәм» муниципаль программасы яшьләрне Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

Соңгы елларда Баулы муниципаль районында кече һәм урта бизнесны үстерү сизелерлек активлашты. Әмма дөньякүләм икътисадый рецессия шартларында икътисадта, бизнеста, тулаем җәмгыятьтә активрак роль уйнарга сәләтле яшь эшмәкәрләрнең яңа буынын формалаштыруга ихтыяҗы арта. Хәзерге этапта яшьләр эшкуарлыгын үстерү квалификацияле кадрлар әзерләүгә генә түгел, ә Баулы муниципаль районының инновацион үсеш юлына тизрәк күчүенә дә ярдәм итәргә тиеш.

## III. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаның максаты: Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә яшьләрне җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә яшьләрне мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү;

- эшкуарлык эшчәнлегенең уңай имиджын һәм абруен булдыру;

- эшлекле яшьләр өчен уку-укыту программаларын эшләү һәм гамәлгә кертү;

- үз бизнес-проектларын әзерләү һәм яклау күнекмәләрен үстерү.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау Баулы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Программаның гамәлдә булу чорына финанслауның гомуми күләме - 50 мең сум, шул исәптән:

2021 ел – 10,0 мең сум;

2022 ел – 10,0 мең сум;

2023 ел – 10,0 мең сум;

2024 ел – 10,0 мең сум;

2025 ел – 10,0 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз булып тора һәм, тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмә кертелергә тиеш, шулай ук программа чараларын финанслауга федераль һәм республика бюджетларыннан акчалар бүленергә тиеш.

## V. Программаны тормышка ашырудан көтелгән нәтиҗәләр

Программа социаль һәм икътисадый характерга ия, бу Баулы муниципаль районы үсеше өчен максималь социаль-икътисадый нәтиҗәгә ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

Финанс һәм икътисадый тотрыксызлык шартларында халыкның мәшгульлеге структурасы һәм дәрәҗәсе үзгәрүен исәпкә алып, Программаны гамәлгә ашыруның социаль өлкәдә уңай нәтиҗәләре кече һәм урта эшкуарлыкның гамәлдәге субъектларын саклап калуда, аларны яңаларын булдыру исәбенә арттыруда, ялланып эшләүчеләр санын киметүне булдырмауда, яшьләр өчен яңа эш урыннары булдыруда чагылыш табачак.

Программаны гамәлгә ашыру Баулы муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк, шул исәптән:

- эшкуарлык эшчәнлеге өлкәсендә яшьләрне мәгълүмати тәэмин итү системасын үстерү;

- яшь эшмәкәрләргә ярдәм итү чараларында (форумнарда, түгәрәк өстәлләрдә, ачык лекцияләрдә һ.б.) катнашкан яшь кешеләр санын 500 кешегә кадәр арттыру;

- социаль киеренкелекне киметү;

- эш урыннары санын арттыру;

- яшь кешеләр тарафыннан булдырылган коммерцияле предприятиеләрнең табыш күләмен арттыру.

VI. Программаны тормышка ашыру чаралары

| № п/п | Чара исеме | Тормышка ашыру сроклары | Чыгымнар суммсы, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Всего: |
| 1. | Тематик чаралар үткәрү | 2021-2025 еллар | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 50,0 |
| 2. | «Яшь эшкуар мәктәбе»н төзү | 2021г. | - | - | - | - | - | - |
| 3. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, җирле үзидарә органнары катнашында «түгәрәк өстәлләр», семинарлар үткәрү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - |
| 4. | Районда эшкуарлыкны үстерүне массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктырту | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - |
| 5. | Районда эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендә уздырыла торган чараларны мәгълүмати тәэмин итү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - |
| 6. | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, конкурсларда катнашуга җәлеп итү | 2021-2025 еллар | - | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы: | | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 50,0 |